РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
БУИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

21 март 2022 ел Буа шәһәре № 3-26

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Әлши, Боерган авыл җирлекләре
генераль планнарын әзерләү кирәклеге булмау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 18 статьясындагы 6 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Әлши, Боерган авыл җирлекләре территориясендә комплекслы социаль-икътисадый үсеш программалары һәм территориаль планлаштыру схемасы булмауга бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Әлши, Боерган авыл җирлекләренең генераль планнарын эшләүдә ихтыяҗ булмавын танырга.
2. Әлеге карар имза салынган көннән законлы көченә керә һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземдә калдырам.

Буа муниципаль районы
башлыгы, Совет рәисе Р.Р. Камартдинов